РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

31.03.2022 ел №97

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең социаль гарантияләрен тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне җайга салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 26 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карарына (2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада:

- I «Район башлыгының, район башлыгы урынбасарының, депутатларның, Татарстан Республикасы җирле үзидарә сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт хакы» бүлегендә 3 пунктны бәян итәргә: «3. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләкләүләр, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр бирелергә мөмкин.»;.

1.2. II бүлектә. 1 пунктны бәян итәргә: «1. Муниципаль хезмәткәрләрнең акчалата керемено муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы нигезендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладын (алга таба – вазыйфаи оклад), тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, муниципаль хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр, ай саен акчалата бүләкләү, сыйныф чины өчен айлык өстәмә, еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү, матди ярдәм, хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләү, төп вазифаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) керә торган муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләү, профильле фәнни дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә керә.»;

1.3. III «Муниципаль район муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру» бүлегендә бәян итәргә:

- 1 пунктның 3 пунктчасы: «3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәгеләрдән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

югары муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 9 проценты;

төп муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 7 проценты;

әйдәп баручы муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 5 проценты;

өлкән муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 3 проценты;

кече муниципаль вазыйфалар өчен - вазыйфаи окладның 1 проценты.»;

- 1 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) вазыйфаи окладның 1 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын гамәлгә кертү белән бәйле җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда муниципаль хезмәткәрне ул биләгән вазыйфадан азрак вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгән очрактан тыш, бу очракта акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата керемен ул элегрәк биләгән вазыйфасы

буенча акчалата кереме күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.»;

Түбәндәге эчтәлекле 7) һәм 8) пунктчалар өстәргә:

- 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7) төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) керә торган муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү.

Әлеге түләү хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау керә торган муниципаль хезмәткәргә башкарыла;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә: «8) хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләү, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.»;

1.4. Карарга 10 нчы кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. Карарга 11 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.6. Карарга 13 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин

10нчы кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2018 елның 24 апрелендәге
149 номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы; 2022 елның 31 мартындагы 97 номерлы карары редакциясендә)

## Профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Өстәмә билгеләү өчен нигез булып муниципаль вазыйфаны биләүче затта, муниципаль хезмәткәрдә тиешле документ белән расланган профильле гыйльми дәрәҗә булу тора.

Профильле гыйльми дәрәҗә буенча таләпләр җирле үзидарә органнары функцияләре белән билгеләнә һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Өстәмә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) фән кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1,5 процентыннан артмаган күләмдә;

б) фән докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2,0 проценттан артмаган күләмдә.

3. Өстәмәне исәпләү ай саен башкарыла һәм җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары хисабына акчалата тәэмин итү белән бергә түләнә.

4. Өстәмә гыйльми дәрәҗә бирүне раслаучы тәкъдим ителгән документ нигезендә билгеләнә. Муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка, муниципаль хезмәткәргә өстәмә билгеләү турындагы актның гамәлдә булуы, әлеге карар гамәлдә булган очракта, аның вазыйфасында эшләгән бөтен чорына кагыла.

5. Муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка өстәмә билгеләү турындагы карар ул хезмәт иткән җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

Башкарма комитет җитәкчесенә - муниципаль район башлыгы тарафыннан гыйльми дәрәҗә профильлеге буенча таләпләр нигезендә.

11нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2018 елның 24 апрелендәге
149 номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы; 2022 елның 31 мартындагы 97 номерлы карары редакциясендә)

Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү күләмнәре

| Татарстан Республикасы дәүләт муниципаль хезмәте вазыйфалары төркеме | Вазыйфаи окладка процент ставкалары күләме |
|---|---|
| Югары муниципаль вазыйфалар | 8 |
| Баш муниципаль вазыйфалар | 6 |
| Әйдәп баручы муниципаль вазыйфалар | 4 |
| Өлкән муниципаль вазыйфалар | 2 |

2. Муниципаль хезмәткәргә өстәмә билгеләү турындагы карар ул хезмәт итә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

13нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2020 елның 29 октябрендәге 8 номерлы; 2022 елның 31 мартындагы 97 номерлы карары редакциясендә)

Нормалаштырылмаган
хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен, юридик эш өчен өстәмә һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләү билгеләү һәм исәпләү
тәртибе

1. Муниципаль хезмәткәргә хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләү, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи окладның 2,5 процентыннан артмаган күләмендә билгеләнә.

2. Түләүне исәпләү ай саен башкарыла һәм ул акчалата тәэмин итү белән бергә җирле үзидарә органының (муниципаль орган) хезмәтенә түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

3. Муниципаль хезмәткәрләргә түләү билгеләү турындагы карар җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, ә Башкарма комитет җитәкчесенә - район башлыгы тарафыннан түләү билгеләү турында карар кабул ителә.